ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«15»декабрь 2020 ел № 133-р

Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс игълан итү турында

Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 23 гыйнварындагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе җитәкчесенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә;

2. Конкурска документларны кабул итүне 2020 елның 19 декабре 8.00 сәг 2021 елның 15 гыйнвары 16 сәг кадәр Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы администрациясе бинасында (Әгерҗе шәһәре, Гагарин урамы, 13 йорт, 2 нче кабинет), шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен башкарырга, тел. 2-31-00;

3. 7 кешедән торган конкурс комиссиясен расларга (1 нче кушымта).

4. Конкурс комиссиясенә 2011 елның 18 гыйнварында вакантлы вазыйфаны биләп торуга кандидатларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрергә.

5. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенә “Әгерҗе хәбәрләре” район газетасында һәм Әгерҗе муниципаль районы agryz.tatarstan.ru рәсми сайтында конкурс турында игълан урнаштырырга

6. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.12.2020 № 133-р
күрсәтмәсенә кушымта

Конкурс комиссиясе составы

1. Акбашев А.Э. – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;
2. Закирова Р.А. - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе (килештерү буенча), комиссия рәисе урынбасары;

Комиссия әгъзалары:

1. Хәкимова Н.М. – Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар бүлеге башлыгы, комиссия секретаре;
2. Фәтхетдинова Л.Г. - Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын юридик бүлеге башлыгы;
3. Рыкова Э.Р.- Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе;
4. Мурзин С.Е. – Әгерҗе районында Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе (килештерү буенча);
5. Абзалиева Д.З. - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы каршындагы дини һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү советы әгъзасы, "Татмедиа» ААҖ филиалы “Әгерҗе хәбәрләре” газетасы редакциясе мөхәррире (килештерү буенча)